Ә сез беләсезме?

ХАЖ - ОЛУГ ФАРЫЗ ГЫЙБАДӘТЛӘРНЕҢ БИШЕНЧЕСЕ

Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН

“Кешеләр арасында хаҗга баруның кирәклеге турында хәбәр тарат, алар җәяүләп тә, озын юл йөреп арыган дөяләргә атланып та килер”, диелә Коръән кәримнең “Хаҗ” сүрәсенең 27нче аятендә. Хаҗ кылган кеше турында пәйгамбәребезнең хәдисе: “Бер кеше Аллаһ ризалыгы өчен хаҗ кылса, бозык сүзләр сөйләшмәсә һәм бозык булган эшләр кылмаса, ул анасыннан туганда ничек гөнаһсыз иде, шулай гөнаһсыз булып калыр, ягъни бөтен гөнаһы ярлыканып, анасыннан тугандагы кебек пакьләнеп калыр”. Мөмкинлеге була торып та хаҗга бармау гөнаһ санала.

Кәгъбә - мөселманнарның Мәккәи Мөкәррәмдәге изге йорты, әл-Мәсҗид әл-Хәрәм, ягъни изге мәчете. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: “Хактыр ки, адәмнәр өчен салынган вә тугры юл күрсәтүче беренче йорт ул, әлбәттә. Мәккәдәге йорт (Кәгъбәдер). Анда ап-ачык аятьләр, Ибраһим баскан җирләр бар. Анда кергән кеше иминлектә булыр. Юлын тапкан (көче җиткән, хәленнән килгән) кешеләрне Аллаһ анда (хаҗга) барырга бурычлы итте”, ди (“Гыймран” сүрәсе, 96, 97нче аятьләр). Дөнья йөзендәге барлык мөэмин-мөселманнар намазларын кыйблага - Мәккә шәһәрендәге Кәгъбәгә юнәлтеп укый.

Гарәп-фарсы галимнәре, географ һәм тарихчылары әт-Тәбари, әл-Мукатдиси, әл-Идриси, әл-Масуди, Ибн Фазлан, Ибн Батута һәм башкаларның хезмәтләрендә ата-бабаларыбызның хаҗ кылыуы, алар яшәгән авыл, шәһәрләрдә мәчет һәм мәдрәсәләр булыуы турында хәбәр ителә.

Ата-бабаларыбызга хаҗ кылу өчен атта, дөядә, яисә җәяүләп меңнәрчә чакрым юл үтәргә кирәк булган. Мөселман озайлы сәфәргә чыккан, кайберләренә туган йортына кайту бәхете тимәгән. Аларның ничек хаҗ кылулары турында хаҗнамә, сәяхәтнамә яки сәфәрнамәләрдән ачык күренә. Безнең көннәргә килеп җиткән иң беренче хаҗнамәне Мортаза бине Котлыгша әс-Симети (ул “Иман шарты”ның авторы) язган. Бу хаҗнамә 1697-1698 елларга карый. 1902 елда Ризаэтдин Фәхретдин тарафыннан басылган “Рихләт әл-Мәрҗани” (“Мәрҗанинең сәяхәте”) XIX гасырдагы киң билгеле чыганак булып тора. Дин галиме, философ, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин мәрҗани 1880 елның 31 августында башланган сәфәре вакытында төрле илләрдән юлланучы хаҗиларның Коръәнне ничек укулары, төрле мәзһаб вәкилләренең ничек гыйбадәт кылуларын өйрәнгән.

Хәмидулла Альмушевның 1899 елдагы юлъязмасы Русиядә тиңе юк хаҗнамә. Ул төрек хәрбиләренең бәдәвиләр һөҗүменнән кәрваннар һәм хаҗиларны якламавы, Мәккә шәһәрендә



яшәүче милләттәшләре, мөһаҗир татарлар турында яза. Аңардан тыш 1895 елда Джиддада Русия империясе консуллыгы тәрҗемәче-дипломаты Шакирҗан Ишаев тарафыннан язылган хаҗ турында хикәят бар. Ул үзе үткән бөтен юлны, сәфәрдәге кыенлыкларны бәян итә.

1898-1899 елларда хаҗ гыйбадәтен өйрәнү нәтиҗәсендә штабе-капитан Габделгазиз Дәүләтшин яшерен “Отчет” төзи. Ул Русия хөкүмәтенә хаҗ турында җентеклерәк белү өчен кирәк була. Үзләренең хаҗ сәфәрләре турында галимнәр Морат Рәмзи (Мәкки), Муса Биги, Габдерәшит Ибраһим, Әбделмәних Каргалый, Гали Чокрыйлар да яза.

Мөселман булмаган кешеләрдән 1853 елда Кәгъбә эченә Бөек Британия сәяхәтчесе, язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, этнограф, капитан Ричард Френсис Бертон (1821-1890) гына үтеп керә алган. Аның “Әл-Мәдинә һәм Мәккәгә хаҗ” әсәре 1872 елда урыс теленә тәрҗемә ителә. Капитанның язмаларында ул булган шәһәрләр, анда яшәүче халык, Ислам дине, хаҗ гамәлләре, гарәп мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре турында бай мәгълүмат бирелә. Ричард Бертон үзенең юлдашы, Русиядән булган, “ниндидер сәбәпләр белән Мисыр башкаласына күчкән” хаҗи Вәли турында яза. Хаҗи Вәли ярдәме белән үзен мөселман итеп күрсәтүче Бертон барлык Ислам дине йолаларын дөрес үтәгән, изге шәһәргә үтеп керә алган.

Башкортостан Үзәк тарих архивында дин әһелләренә кагылышлы байтак үзенчәлекле документлар бар. Алар арасында имам һәм мөәзиннәрне тәгаенләү, аларның белемнәрен тикшерү, авылда мәхәллә төзү һәм мәчет ачу турындагылары байтак. Мәккәгә хаҗ кылу өчен имам яки азанчы вазыйфасыннан азат итүне сорап язган рапортлар да очрый. Бу аңлашыла да,чөнки ул заманда хаҗга бару һәм аннан кире әйләнеп кайту өчен байтак вакыт кирәк булган. Хаҗга барырга теләүче башта Ырынбур мөселманнар Диния мәҗлесенә мөрәҗәгать иткән. Диния нәзарәтеннән ул чит ил паспорты алу хокукын бирүче танытма алган. Аннары Уфа губернаторына паспорт алу турында мөрәҗәгать әзерләнгән. Уфа губернаторы канцеляриясе полиция идарәсе белән бу турыда хат алышкан. Чит ил паспорты белән “губернатор рөхсәт итте” дигән танытма да бирелгән. Паспорт алу шулай катлаулы һәм күп акча таләп итә, шуңа күрә хаҗ кылучылар күп булмый. Архив материалларыннан күренүенчә, Диния нәзарәтенең барлык руханилары да хаҗ кылган.

Диния нәзарәтенең өченче мөфтие Габделвахмит хәзрәт Сөләйманов 1861 елда хаҗ кыла. Әгәр элек мөфтиләр хаҗга аерым кеше сыйфатында барган булсалар. Диния нәзарәтенең бишенче мөфтие Мөхәммәлъяр хәзрәт Солтанов аны беренче булып рәсми рәвештә кыла - 1893 елның февралендә Уфадан 5 кешелек делегация җитәкчесе сыйфатында хаҗ сәфәренә юллана. Алар 9 мартта Истанбул шәһәренә барып җитә. 19 мартта мөфтине төрек солтаны Габделхәмид II кабул итә, ул Русия мөселманнарының хәлләре турында сораша. Солтан Мөхәммәдъяр хәзрәтне Төркиянең II дәрәҗә Госмания ордены белән бүләкли. Габделхәмид II Русия мөселманнарына пәйгамбәребез Мөхәммәт әманәтеннән өлеш чыгарырга боерык бирә. Пәйгамбәрнең төкләрен балавызга утыртып катырганнар, гаять зур ихтирам һәм пөхтәлек белән эшләнгән, эче ефәктән, тышы фил сөягеннән гыйбарәт кыйммәтле сандыкка салынган бу бүләкне мөфти Мөхәммәлъяр Солтановка тапшыралар. Уфада бу тарихи истәлек бүләк утта янмый торган сандыкта саклана.

Җиденче мөфти Галимҗан хәзрәт Баруди 1887 елда хаҗ кыла, Мәккәгә барышлый Истанбулда һәм Каһирәдә була. Сигезенче мөфти, мәшһүр фикер иясе, язучы, мәгърифәтче, галим һәм дин эшлеклесе Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдин 1926 елда Мәккәдә үткән Бөтендөнья мөселманнары конгрессына СССР делегациясе җитәкчесе сыйфатында бара.

1927 елда “Ислам” (1926 елга кадәр “Ислам мәхәлләсе”) журналында Ризаэтдин Фәретдиннең конгресска баруы турында язмалары басыла. Аның тикшеренүләреннән күренүенчә, һәр мөэмин мөселман, җәмгыятьтә дини статуска ия шәхес хаҗ кылган.

Русиядә хаҗ кылу һәм Мәккәгә барырга паспорт алу өчен беренче указга император Александр Беренче 1803 елның 23 мартында кул куйган. XIX гасырның 70нче елларыннан XX гасыр башына кадәр Русия подданныйлары - мөселманнарның хаҗ кылу мәсьәләсе Чит ил эшләре министрлыгы, Константинопольдәге илчелек, 1891 елда ачылган Җиддәдәге консуллыкта актив тикшерелгән. Моннан тыш, бу мәсьәләне хәл итүгә Русиянең мөселманнар күмәк яшәгән төбәкләре җитәкчеләре дә җәлеп ителгән, XX гасыр башына хаҗиләр саны арта. Аларның исәбе алып барыла башлый, хаҗ хәрәкәтен күзәтү өчен мөмкинлек туа. Русия власте мөселманнарга паспортны зур кыенлык белән биргән. Шуңа күрә күр кенә хаҗилар,элекке кебек паспортсыз чит илгә чыкканнар. Власть “хаҗ Төркиягә зур матди файда китерә, ул акча соңыннан хәрби максатларда кулллланыла”, дип исәпләгән. Алып барылган исәп алу да борчуга салган, әлбәттә, XIX-XX гасырларда 8-12 мең Русия мөселманы ел саен хаҗ кылган. Бу әле исәпкә алынганнары, күпләр паспортсыз да юлга чыккан.

Дәвамы бар.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

Зөлхиҙә 2014 миләди йыл
1435 һижри йыл.

Зөлхиизә	Аҙна көндәре	Сентябрь Октябрь	Иртәнге намаҙ	Ҡояш сығa	Өйлә нам.	Икен. нам.	Аҡшам.	Йәстү намаҙы
1	Кесе йома	25	6.38	8.08	14.30	18.36	20.06	21.36
2	Йома	26	6.40	8.10	14.30	18.33	20.03	21.33
3	Шәмбе	27	6.42	8.12	14.30	18.31	20.01	21.31
4	Йәкшәмбе	28	6.44	8.14	14.30	18.28	19.58	21.28
5	Дүшәмбе	29	6.46	8.16	14.30	18.26	19.56	21.26
6	Шишәмбе	30	6.47	8.17	14.30	18.23	19.53	21.23
7	Шаршамбы	1	6.49	8.19	14.30	18.21	19.51	21.21
8	Кесе йома	2	6.51	8.21	14.30	18.18	19.48	21.18
9	Йома	3	6.53	8.23	14.30	18.16	19.46	21.16
10	Шәмбе	4	6.55	8.25	14.30	18.13	19.43	21.13
11	Йәкшәмбе	5	6.57	8.27	14.30	18.11	19.41	21.11
12	Дүшәмбе	6	6.59	8.29	14.30	18.08	19.38	21.08
13	Шишәмбе	7	7.01	8.31	14.30	18.06	19.36	21.06
14	Шаршамбы	8	7.03	8.33	14.30	18.03	19.33	21.03
15	Кесе йома	9	7.05	8.35	14.30	18.01	19.31	21.01
16	Йома	10	7.07	8.37	14.30	17.58	19.28	20.58
17	Шәмбе	11	7.08	8.38	14.30	17.56	19.26	20.56
18	Йәкшәмбе	12	7.10	8.40	14.30	17.53	19.23	20.53
19	Дүшәмбе	13	7.12	8.42	14.30	17.51	19.21	20.51
20	Шишәмбе	14	7.14	8.44	14.30	17.49	19.19	20.49
21	Шаршамбы	15	7.16	8.46	14.30	17.46	19.16	20.46
22	Кесе йома	16	7.18	8.48	14.30	17.44	19.14	20.44
23	Йома	17	7.20	8.50	14.30	17.41	19.11	20.41
24	Шәмбе	18	7.22	8.52	14.30	17.39	19.09	20.39
25	Йәкшәмбе	19	7.24	8.54	14.30	17.37	19.07	20.37
26	Дүшәмбе	20	7.26	8.56	14.30	17.34	19.04	20.34
27	Шишәмбе	21	7.28	8.58	14.30	17.32	19.02	20.32
28	Шаршамбы	22	7.30	9.00	14.30	17.30	19.00	20.30
29	Кесе йома	23	7.32	9.02	14.30	17.27	18.57	20.27
30	Йома	24	7.34	9.04	14.30	17.25	18.55	20.25

РИВАЯТЬ

Бер мөселман таң намазын мәчеттә укырга дип иртүк торган. Чистартынып, киенеп юлга чыккан. Тик юлда егылып, киемен пычраткан. Кире әйләнеп кайтып, чистартынып киемен алыштырган һәм янә юлын кабатлаган. Шул урында яңадан егылып, кире кайтып китәргә мәҗбүр булган. Инде өченче кат юлга чыккач, юлында лампа тотып яктыртып торган кешегә тап булган. “Синең мәчет юлында ике тапкыр егылганыңны күргәч, юлыңны яктыртып барырга булдым”, - дигән таныш булмаган бәндә. Шулай икәүләп гыйбадәт йортына киткәннәр. Мәчеткә килеп җиткәч, өч кат юлга чыккан кеше яңа танышын мәчеткә намазга чакырган. Берничә тапкыр чакыруны кире кагуга, гаҗәпләнеп, ни өчен аның намаздан баш тартуын сораган. “Мин - шайтан, - дигән лампалы танышы. - Син минем аркада ике тапкыр егылып киемеңне пычраттың. Беренче тапкыр егылып, юлыңны кабатлагач, Аллаһы Тәгалә синең барлык гөнаһларыңны ярлыкады. Мин сине яңадан егылырга мәжбүр иттем. Ләкин бу да сине туктатмады, янә мәчеткә киттең. Шунда Аллаһы Тәгалә синең барлык өй әһелләреңнең гөнаһларын кичерде. Мин син тагын егылсаң, барлык авылдашларыңның гөнаһлары кичерелер дип курыктым һәм мәчеткә егылмый баруыңны тәэмин итәргә тырыштым”.